


Шәһәрләрдә чvп контейнерлары кvп, аларны аерым яраклаштырылган машиналар алып китә. Ә авылларда алар кирәкме?
Гомуммән алганда, кvп кенә авылларда ул контейнерлар бар. Аларны чыгарган очен кvпмедер кvләмдә акча тvләргә туры килә. Шуна кvрә, кайберләре тиеннәрен санагач «остәмә баш авыртуы» дип карый бу мәсьәләгә. Районнар буйлап йоргәндә, монаеш игътибар ителә: кайбер авылларда чvплекләр авыл башында, ерактан ук кvзгә ташланып торалар.

Алар авылнын бар ямен, матурлыгын бозып тора. Шул максаттан дәvләт тарафыннан легаль булмаган чvплекләр бетерелә башлады. Чvп жыю эше 2016 елнын 1 гыйнвареннан лицензиясе булган махсус оешмаларга тапшырылды, ә авыл жирлекләре - чvп тvгv эшен оештыручылар гына.
Законсыз урынга чvп, конкvреш-кирәк яраклары калдыклары ташлау махсус закон нигезендә кvзәтелә. Законны санга сукмаучы гражданнарга  – штраф каралган. Юридик зат булып теркәлмичә шәхси эшчәнлек алып баручыларга исә ул 30-50 мен сум тирәсе, яки эшчәнлекне 90 тәvлеккә кадәр туктатып тору белән яный. Экологик таләпләрне тогәл vтәмәгән юридик затларны 100-200 мен кvләмендә штраф белән куркыталар.
Авыллардагы чисталыкны экология хезмәткәрләре контрольгә алып торса да, бу, кvбесенчә, авыл жирлеге башлыклары карамагында. Рузаевка районы Татар Пешләсе авылында (бер урамнын берничә урынында ) чvп контейнерлары урнаштырылган. Электәгечә елга-кvл буйлары, кычыткан араларына чvп ыргытучылар азайды. Чvпләрне ташу исәп-хисап суммасы – кеше башына кырык сумга якын. Хәзер Пешлә халкы да, шәһәр кешесе кебек vк, билгеле тариф буенча, чvп тvккән очен акча тvли. Шулай ук Ләмберә районы Пензятка, Татар Тавласы һәм башка берничә авыл халкы мусор чыгарган очен акча тvлиләр. Дорес, чvп тvгv контейнерлары һәр авылда да бар, дип әйтеп булмый. Бу авыл халкынын ризалыгы белән генә эшләнә. Кvп очракта алар мона каршы. Барысы да акчага барып терәлә. Кvпләр “минем тvгәрлек чvбем юк”, дип каршы тошә, икенчеләре “без чvпне жиргә кvмәбез”, диләр. Ләмберә районы Татар Свәрби авылында да чvп контейнерлары юк. Авылдагы ялкау хужалык,  “дачный домик” дип аталганнарынын берничәсенен ой трәләре бик ук чиста тvгеллеген кvреп vткән идем. Бу гасырдан-гасырга чиста-похтә дип әйтелеп килгән татар кешесенә бер дә хас булмаган әйбер.

Кадошкино районы Латышовка авылы житәкчесе Римма Амин кызы Арюкова авылнын урамнары буенча биш махсус контейнер урнаштырганнар, ди. Атна саен, ягъни аена дvрт тапкыр ЖКХ хезмәткәрләре жыелган чvпне килеп алалар. Алар шунын очен vз керемнәеннән (свои доходы) аена 3-3, 5 мен акча тvләп баралар. Элегрәк чvпне теләсә кая ташлап, колактан чvпкә бата идек. Ә хәзер авылнын яме дә, тәртибе дә бар, ди житәкче.
Шул ук районнын Иса авылында да элегрәк контейнерлар урнаштырган иде, акчалары булмаганга алдырганнар. Хәзер чvпне һәр кеше авылдан читтә казылган чvп базына илтә, йорт тирәсен жыештырып тора.
Атюрьево районы татар авылларында да чvп контейнерлары юк. Алар чvпләрен «свалка» дигән жиргә тvгәләр.
– Безнен авылда андый контейнерлар юк, – ди Атюрьево районы Кыштыру авылыннан Эльвира Хәйдәр кызы Совешова. – Кайбер авылларда чvпне пакетка салып, капка алдына чыгарып куялар да, билгеләнгән коннәрдә махсус машина жыеп китә икән, ә кайберләрендә контейнерлар урнаштырылган. Бездә әле андый тәртипләр кермәде. Шулай да авылыбыз бик чиста. Тегендә-монда аунап яткан чvп-чар кvзгә ташланмый. Барлык чvпне, конкvреш кирәк-ярагы калдыкларын авылдан читтәге махсус урынга илтәбез. Яндырып була торганын яндырып юк итәбез.

**Н.Хәлил**